Духовно-просветительская газета

Индекс 52381

**Котлыйбыз!**

## Кошки районы мәчете имамы Әнвәр хәзрәт Хәйруллиның туган көне

Хөрмәтле Әнвәр хәзрәт!

**Сезнең тырышлыгыгыз белән Кошки авылы һәм Погрузная станциясе мөселманнары үз мәхәлләләрен булдырдылар.**

**Халыкның күмәк көче белән мәчет салынды. Ул, дин учагы буларак, җирле мөселман халкын үзенә тартып тора. Биредә һәркемгә иманын камилләштерү һәм Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычын үтәү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Монда Сезнең өлешегез дә зурдан. Сез - безне Исламга әйдәүче, дини йолаларыбызның сагында торучы дин әһеле.**

**Киләчәктә дә халкыбызның динлелеген кайгыртып, бергәләп эшләү өчен Сезгә иман байлыгы, тән саулыгы, ышанычлы дуслар, фикердәшләр ярдәмен тоеп яшәргә Аллаһы Тәгалә насыйп итсен иде. Тормышыгыз бәхетле, хезмәтегез уңышлы булып, балаларыгызның, оныкларыгызның игелеген күреп, озын һәм тыныч гомер кичерүегезне телибез.**

***Самара өлкәсе Диния нәзарәте,***
***Самара Җәмигъ мәчете,***
***Кошки авылы һәм Погрузная станциясе мөселманнары.***
***Туганнарыгыз, дусларыгыз, якыннарыгыз.***

**Табиб мөнбәре**

## Файдалы киңәшләр



### *Колак авыруларын дәвалау*

**Үлек килүдән:**

*Суган измәсенә яки согына бераз гына җитен мае яки атланмай кушып, шушы катнашмага манып колакка тампон кую үлек акканда файдалы.*

*Дару ромашкасы үләне төнәтмәсе. 1 чәй кашыгы кипкән үләнне бер стакан суда тотып, сөзгәч, колакка тамызырга.*

*Кәҗә сакалы тамырының согын сыгып, үлекләгән колакка тамызалар, җәрәхәтне төзәтер, үлекне бетерер.*

**Сызлаудан:**

*Горчица согын сызлаган колакка тамызу файдалы. 10-15 г әче әремне 1 стакан су салып кайнатып, сызлаган колакны шуның пары өстендә тотарга.*

*Ак тупыл яфрагы согын сыгып, бераз җылытып тамызу файдалы.*

*Чөгендер согын җылытып колакка тамызырга.*

**Колак шаулаудан:**

*Торма согы һәм мае тамызу файдалы.*

*Укроп согы тамызу шаулап авыртканны бетерә.*

**Колак җәрәхәтле чакта:**

*Эренләп ишетмәс булган колакка бакыр окисе порошогын өрү андагы җәрәхәтне төзәтә.*

*Балтырган чәчәге согын тамызырга.*

*10 г әнечне төеп, 50 г гөлҗимеш мае белән катнаштырып, җәрәхәтле колакка салу файдалы.*

**Саңгыраулыктан:**

*20 г артыш җиләген 50 мл көнҗет маена салып, савыты каралганчы тимер савытта кайнаталар, аннары шул майны җылымса көе колакка тамызалар.*

*Елга буе талы согын колакка тамызсаң, аны чистарта, чукраклыктан дәва була.*

*Чи карама тамырының бер башын утка тыгарга, ә утта булмаган башыннан аккан сыекчаны җыеп барырга. Шуны авырудан чукракланган колакка җылы килеш салырга.*

***Фәния ХУҖАХМӘТ.***
***(«Һәр авыруга дәва бар» китабыннан)***

**Бәйрәмнәребез**

## Балалар Сабантуе - күңелле бәйрәм




Быел Кинель-Черкассы авылының «Колос» санаторий-лагерында 130 татар һәм башкорт баласы ял итте. Алар ике отряд булып Самараның «Нур» мәдрәсәсе мөгаллимнәре, шәкертләре кулы астында дини мохиттә тәрбияләнделәр.

Җәйге ялда балалар күңеленә кыска вакыт эчендә зур тәрбия һәм гыйлем сеңдерелә. Алар хәләлне хәрәмнән аерырга, намаз кагыйдәләренә, мөселманча тормыш рәвеше алып барырга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр.

5 июльдә "Колос" санаториесенең бөтен сменасы (250 бала) өчен өлкә Диния нәзарәте, Самара региональ «Дуслык», Самара шәһәр "Ак бәхет" иҗади-иҗтимагый оешмалары тарафыннан татар милли бәйрәме Сабантуй оештырылды. Икенче ел рәттән "Дуслык" оешмасы җитәкчесе — «Алия-фарм» даруханәләр челтәре генераль директоры, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы Фәхретдин Бәдретдин улы Канюкаев бәйрәм бәйгесендә катнашучылар өчен бүләкләр тәкъдим итте.

Бәйрәмне "Дуслык" оешмасы вице-президенты Фәрхәт Мәхмүтов һәм аның хәләл җефете Альбина татар һәм рус телендә алып бардылар.

Чараны өлкә мөфтие урынбасары Талип хәзрәт Яруллин, "Колос" лагеренда татар балалары тәрбияләнгән отрядларны җитәкләүче Радик Газизов, "Дуслык" оешмасы вице-президентлары Фәрхәт Мәхмүтов, Рәфыйк Бәдәмшин, "Ак бәхет" оешмасы рәисе Римма Нуретдинова, "Дуслык" оешмасы каршында эшләп килүче яшьләрне җитәкләүче Гүзәл Сәлахова сәламләү сүзләре белән ачып җибәрделәр.

Тиздән Сабантуй урынын балачага сырып алды. Мәйдан кырмыска күчен хәтерләтте. Кызлар һәм малайлар өчен төрле бәйгеләр оештырылган иде. Кашыкка йомырка салып яисә капчык киеп йөгерү, җепкә эленгән бүләкне күз бәйләп кисеп алу, кәянтәгә чиләк асып су ташу, бау тартышу, катыктан тәңкә эзләү... Ярышлар санап бетергесез булды.

Кызыклы бәйгеләрдә үзләрен дин әһелләре һәм лагерь хезмәткәрләре дә сынап карарга булдылар.

Шулай ук биредә "Дуслык" оешмасы яшьләре башкаруында туган җирләренә, телләренә, әти-әниләренә багышланган җырлар да яңгырады. Бәйрәм дәвамында кунаклар пылау һәм шашлык авыз иттеләр.

**Самара шәһәренең "Ак бәхет" оешмасы рәисе**
***Римма НУРЕТДИНОВА.***

***Уважаемые читатели!***

***В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.***

***Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.***

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.
**АДРЕС РЕДАКЦИИ И ИЗДАТЕЛЯ:** 443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54. Соборная мечеть. Телефон: 932-58-67. Электронный адрес: islam-nur@bk.ru

**Редактор** - Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
**Корреспондент** - Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Ответственные за выпуск газеты:**
**по организационно-финансовым вопросам** - Джавдят ШАРАПОВ,
**по духовно-просветительской части** - Наиль СУЛЕЙМАНОВ.
**Набор и верстка** - Рамиль НУРЕТДИНОВ.
**Корректор** - Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**

***по установленному графику - 17 июля 15.00,***

***фактически - 17 июля 15.00.***

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**

**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ Тираж 2000.**

***Цена свободная.***
Рег. свидетельство
ПИ № ТУ63-00111